**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 12 августындагы 3344 номерлы карары**

**«Казан шәһәренең Киров районындагы**
**“Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләрен**
**су белән тәэмин итү магистраль челтәрләре» линия объекты**
**территориясен планлаштыру проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, « АБ 1 архитектура бюросы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тәкъдиме буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карарлары нигезендә, территорияне планлаштыру проектын эшләү 2023 елның 6 декабрендәге 846 номерлы гариза кысаларында 2023 елда башлануын исәпкә алып **карар бирәм:**

1. «Казан шәһәренең Киров районындагы “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләрен су белән тәэмин итү магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, планлаштырылган линия объектын урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 12 августындагы
3344 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәренең Киров районында «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проекты**

«Казан шәһәренең Киров районында “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру проектына түбәндәгеләр керә:

I. Территорияне планлаштыру проекты (график өлеш). Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы (1-8 битләр).

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән урнаштыру турындагы нигезләмә.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

# I. Территорияне планлаштыру проекты (график өлеш).

## Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы

(1 бит)



(2 бит)



С
далее см. лист 1
далее см. лист 3
н17
н18
н19
н20
н21
н22
н24
н25
н27
н28
Условные обозначения
-Красная линия
-Контур дороги
-Граница проекта планировки линейного объекта
-Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
- Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
- Граница зоны планируемого размещения линейного объекта
Схема листов
1
2
3
4
5
6
7
8
Лист 2
Формат А4

(3 бит)


С
далее см. лист 2
далее см. лист 4
н29
н30
31
н32
н33
н34
н36
37
н38
н39
н40
Условные обозначения
-Красная линия
-Контур дороги
-Граница проекта планировки линейного объекта
-Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
- Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
- Граница зоны планируемого размещения линейного объекта
Схема листов
1
2
3
4
5
6
7
8
Лист 3
Формат А4

(4 бит)


С
далее см. лист 3
далее см. лист 5
н41
н42
н43
н44
н4
н45
н47
н48
н49
н50
н51
н52
н53
н54
н55
н56
н58
Условные обозначения
-Красная линия
-Контур дороги
-Граница проекта планировки линейного объекта
н1
н2
-Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
В1
- Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
В1
- Граница зоны планируемого размещения линейного объекта
Схема листов
1
2
3
4
5
6
7
8
Лист 4
Формат А4

(5 бит)




*Условные обозначения*

–Красная линия

–Контур дороги

–Граница проекта планировки линейного объекта

н1 н2 –Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта

В1 – Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный

В1 – Граница зоны планируемого размещения линейного объекта

*Схема листов*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|



Формат А4

(6 бит)




Условные обозначения

- –Красная линия
- –Контур дороги
- –Граница проекта планировки линейного объекта
- н1 н2 –Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
- В1 – Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
- В1 – Граница зоны планируемого размещения линейного объекта

Схема листов

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

(7 бит)


С
далее см. лист 6
далее см. лист 8
н85
н87
н89
н91
н93
н95
н97
н88
н90
н92
н94
н96
н98
В1
Условные обозначения
-Красная линия
-Контур дороги
-Граница проекта планировки линейного объекта
н1
н2
-Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
В1
- Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
В1
- Граница зоны планируемого размещения линейного объекта
Схема листов
1
2
3
4
5
6
7
8
Лист 7
Формат А4

(8 бит)




*Условные обозначения*

- –Красная линия
- –Контур дороги
- –Граница проекта планировки линейного объекта
- н1 н2 –Поворотные и характерные точки размещения линейного объекта
- В1 – Проектируемый водопровод хозяйственно-питьевой и противопожарный
- В1 – Граница зоны планируемого размещения линейного объекта

*Схема листов*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

Проект Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 12 маендагы 564 номерлы карары белән расланган бер яки берничә линия объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру составы һәм эчтәлеге турындагы нигезләмә, «Казан шәһәренең Киров районында “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләүгә техник бирем, проектны эшләү вакытында гамәлдә булган Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары нигезендә эшләнде.

Проектлау территориясе Татарстан Республикасының Казан шәһәренең Киров районында урнашкан.

Проект белән «Казан шәһәренең Киров районында “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» объектын Казан шәһәренең Киров районындагы «Серебряный бор» торак комплексы аша «Несмелов урамыннан алып федераль әһәмияттәге М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәр автомобиль юлы» линия объекты территориясен планлаштыру проектының кызыл линияләре коридорында урнаштыру каралган. I этап – Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 13 маендагы 1331 номерлы карары белән расланган Несмелов урамыннан «Серебряный бор» торак комплексына кадәрге участок.

### Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

«Казан шәһәренең Киров районында “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» линия объектын планлаштыру проекты Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында урнашкан территориягә эшләнде.

Территорияне планлаштыру документларын әзерләүнең максаты – «Экорайон» һәм «Хәрби шәһәрчек-32» торак районнары территорияләре өчен су белән тәэмин итү челтәрен төзү.

Проект белән «Казан шәһәренең Киров районында “Хәрби шәһәрчек-32” һәм “Экорайон” территорияләре өчен су белән тәэмин итүнең магистраль челтәрләре» объектын Казан шәһәренең Киров районындагы «Серебряный бор» торак комплексы аша «Несмелов урамыннан алып федераль әһәмияттәге М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәр автомобиль юлы» линия объекты

территориясен планлаштыру проектының кызыл линияләре коридорында урнаштыру каралган. I этап – Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 13 маендагы 1331 номерлы карары белән расланган Несмелов урамыннан «Серебряный бор» торак комплексына кадәрге участок.

Территорияне планлаштыру документларында түбәндәгеләрне төзү каралган:

- магистраль суүткәргеч;
- суүткәргеч насос станциясе.

Тоташтыру ноктасы – Боевая урамында су белән тәэмин итү челтәрләренә (2Ø1200 мм) тоташтыру урыны. Тоташтыру нокталарында суүткәргеч челтәрендәге басым – су баганасында 30 метр.

Суүткәргечнең тоташтыру урыныннан алып проектлана торган суүткәргеч насос станциясенә кадәр диаметры 2Ø 710 мм итеп кабул ителде.

I этап автомобиль юлының (Несмелов урамыннан алып «Серебряный бор» торак комплексына кадәр) транспорт хәрәкәте өлеше белән гамәлдәге коммуникацияләр һәм юллар белән кисешү урыннарындагы күчешләр 2хØ1200 мм футлярларында башкарылган.

Суүткәргеч челтәр 31.1333.2021 кагыйдәләр җыелмасы нигезендә грунтлар туңу тирәнлегеннән түбәнрәк салына.

Челтәрне ачык ысул белән төзү каралган, кисешүләр ачык ысул һәм горизонталь юнәлештә бораулау ысулы белән башкарыла.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасының киңлеге транспортта узу, техника урнаштыру, эшләр башкару, шулай ук алга таба магистральгә техник хезмәт күрсәтү өчен кирәкле габаритларны исәпкә алып формалаштырылды һәм 10 м итеп (кырыйдагы суүткәргеч күчәреннән һәр якка 5 әр м) кабул ителде, бу 42.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасы нигезендә яктыдагы горизонталь буенча инженерлык корылмаларыннан биналарның һәм корылмаларның фундаментларына кадәр норматив ераклыкка туры килә.

Линия объектын урнаштыру өчен билгеләнгән полосаның мәйданы 30676 кв.м (3,07 га) тәшкил итә. Озынлыгы – 4270 м.

Проектлана торган объектның төзелеш төре – яңа төзелеш. Объектны бер этапта төзү каралган.

Линия объектының санитар-сак зонасы санитар-сак зонасының аерым проекты белән эшләнә һәм билгеләнә.

Проект белән «Экорайон» һәм «Хәрби шәһәрчек-32» торак районнарындагы кулланучылар өчен суүткәргеч сулары басымын арттыру максатыннан су үткәрү насос станциясе каралган.

Су үткәрү насос станциясенең урнашу урыны әлеге объектны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 3561 номерлы карары белән расланган «Экорайон» территориясен планлаштыру проектын урнаштыру өчен каралган зонада билгеләнде.

Хуҗалык-эчү өчен, янгынга каршы ихтыяҗларга су бирү белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча проектлана торган суүткәргеч насос станциясе ышанычлылык буенча I категориягә карый, җитештерүчәнлек – 13 954,53 куб.м/тәүлек (максималь сәгатьлек чыгым – 1291,59 куб.м/сәг), бу «Экорайон» һәм «Хәрби шәһәрчек-32» территорияләрен су белән тәэмин итү буенча исәпләнгән гомуми йөкләнешкә туры килә.

Проектлана торган объектның төзелеш төре – яңа төзелеш. Объектны бер этапта төзү каралган.

Объектның санитар-сак зонасы 2.1.4.1110-02 санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә алга таба аерым капиталь төзелеш проектын эшләү юлы белән проектлауның алдагы стадияләрендә билгеләнә.

## Территорияләрендә линия объектын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар билгеләнгән субъектлар исемлеге

Проектлау территориясе Көнчыгыш Европа тигезлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, Идел елгасы үзәнендә, аның сул ярында урнашкан.

Проектлау территориясе административ яктан Татарстан Республикасында, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, шәһәрнең Киров районында урнашкан.

## Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аларны резервлау һәм (яисә) алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Билгеләнеше | Алу/резервлау төре |
|---|---|---|
| 16:50:190301:91 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Резервлау |
| 16:50:280303:8 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Билгеләнеше | Алу/резервлау төре |
|---|---|---|
| 16:50:000000:17380 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:280304:19 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:280304:1 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:10 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:817 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:825 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:550 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:549 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:548 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:547 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:546 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:738 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Билгеләнеше | Алу/резервлау төре |
|---|---|---|
| 16:50:190203:747 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:545 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:746 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:544 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:543 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:542 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:735 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:734 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:733 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:745 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:744 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:541 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |

| **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Билгеләнеше** | **Алу/резервлау төре** |
|---|---|---|
| 16:50:190203:743 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:540 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:742 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:1605 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:538 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:537 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:536 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:5355 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:534 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:533 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:532 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:531 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |

| **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Билгеләнеше** | **Алу/резервлау төре** |
|---|---|---|
| 16:50:190203:827 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:192 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:2005 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:495 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:2002 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:205 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:207 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:840 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:204 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:206 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |
| 16:50:190203:531 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен | Өлешчә резервлау |

## План буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объекты составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 36 статьясындагы 4 өлешенең 3 пункты нигезендә линия объектлары биләгән яисә линия объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә шәһәр төзелеше регламентларының гамәлдә булуы кагылмый. Җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү билгеләнергә тиеш түгел.

Шулай ук объектны план буенча урнаштыру зонасы Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 13 маендагы 1331 номерлы карары белән расланган «Несмелов урамыннан федераль әһәмияттәге М-7 «Волга» автомобиль юлына кадәр «Серебряный бор» торак комплексы аша. I этап – Несмелов урамыннан алып «Серебряный бор» торак комплексына кадәр» линия объекты территориясен планлаштыру проектының кызыл линияләре коридорында урнашуга бәйле рәвештә Казан шәһәреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 23 статьясы нигезендә урам-юл челтәре ярдәмче зонасы өчен территориаль зоналар параметрлары нуль күрсәткече белән билгеләнә.

## Территорияне планлаштыру проектын әзерләгәндә гамәлдәге һәм төзелә торган, саклана торган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын күрү зарурлыгы турында мәгълүмат

Гамәлдәге җир асты коммуникацияләре һәм корылмалары урнашкан урыннарда өслекне ачуга бәйле эшләр әлеге коммуникацияләрне эксплуатацияләүче министрлыклар һәм ведомстволар билгеләгән махсус кагыйдәләрне үтәп башкарылырга тиеш.

Эшләр башланганчы, эксплуатацияләүче оешма эшләрнең барлык зоналары чикләрендә гамәлдәге җир асты коммуникацияләрен ачыклый һәм билгели.

Проект документларында эшләрне башкарганда машина белән бәрелү нәтиҗәсендә гамәлдәге коммуникацияләргә зыян китерү мөмкинлеген булдырмый торган чаралар күрергә кирәк, гамәлдәге җир асты коммуникацияләре өстендә йөрүләрне оештыру урыннарында тимер-бетон юл плиталарыннан каты өслекле вакытлыча юл кичүләрен төзүне күздә тотарга.

Гамәлдәге коммуникацияләр 0,8 метрдан да ким булмаган участокларда төзелгән очракта, куркыныч булу турында кисәтү язулары белән билгеләр куелырга тиеш. Аркылы чыгу урыннары булдырылмаган җирләрдә техника һәм машиналарга йөрү тыела.

Эшләр башкару зонасы чикләрендә гамәлдә булган коммуникацияләр күчәре, туфракны кулдан эшкертү чикләрендә гамәлдәге һәм төзелә торган коммуникацияләр белән кисешү урыннарында билгеләнгән нигезнең факттагы тирәнлеген күрсәтеп, 1,5 дән 2,0 метрга кадәр биеклектәге билгеләр белән беркетелергә тиеш.

Коммуникацияләр күчәрләрен иминлек тамгалары белән билгеләгәнче, эшләр башкару рөхсәт ителми.

Эшләр башланыр алдыннан эксплуатацияләүче оешмага гамәлдәге коммуникацияләр зонасында эшләр башкаруга язма рөхсәт алырга кирәк. Рөхсәтсез яисә гамәлдә булу вакыты узган рөхсәт белән эшләр башкару тыела.

Җир асты коммуникацияләре белән кисешкәндә җир эшләрен эксплуатацияләүче оешмалар вәкилләре катнашында гына кулдан башкарырга кирәк. Торба үткәргечләрдән һәм кабельләрдән 2 м ераклыкта механизмнар белән грунтны эшкәртү тыела.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары белән расланган Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү кагыйдәләрендә билгеләнгән электр челтәре хуҗалыгы объектларын саклау зонасында эшләр башкарганда, төзелеш эшләренә кертү бары тик электр тапшыру линиясен эксплуатацияләүче оешманың рөхсәте булганда гына бирелергә мөмкин.

Электр тогы белән зарарлану куркынычы гамәлдә булган куркыныч зоналарның чикләре 12-03-2001 төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә (Г.2 кушымта)

## Линия объекты урнашуга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

Линия объекты урнашкан территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның дәүләт исәбенә кертелгән мәдәни мирас объектлары юк.

Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру таләп ителми.

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон нигезендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объект, шул исәптән археологик мирас объекты табылган очракта, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр мондый объект ачыкланган көннән алып өч көн эчендә автономияле округның мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы хезмәтенә табылган мәдәни мирас объекты турында язма гариза җибәрергә кирәк.

## Әйләнә-тирәне саклау буенча чаралар башкару кирәклеге турында мәгълүмат

2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы федераль закон нигезендә биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне һәм башка объектларны проектлаганда әйләнә-тирә мохитне пычратуны кисәтү һәм бетерү, әйләнә-тирә мохитне саклауга, табигать мохитен торгызуга, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга һәм аларны торгызуга ярдәм итә торган технологияләр кулланылырга тиеш.

Төзелеш эшләрен уздыру чорында атмосфера һавасына йогынтының төп тискәре факторы махсус техника эше булачак. Эш барышында, шулай ук җир эшләре барышында грунт массалары, эретеп ябыштыру агрегатлары һәм башкалар күченгәндә, техниканың эчке янулы двигательләреннән һавага пычраткыч матдәләр чыгарылачак. Шулай ук төзелеш техникасы эше тавышлы һәм вибрацион тәэсирләргә бәйле булачак, аларның төрләре ачык ысул белән төзелеш эшләрен башкару участоклары тарафыннан локальләштереләчәк.

Атмосфера һавасын пычрату һәм  тавыш йогынтысын  стандарт методикалар буенча исәпләп, шулай ук аналог объектларның күпсанлы мәгълүматларын куллану нигезендә фаразларга мөмкин. Эшләр башкару чорында атмосфера һавасын пычратуның барлык чыганаклары органик булмаган чыганаклар булып тора, чөнки һавага чыгару өчен махсус җайланмалар (торба, вентиляция шахтасы һ.б.) белән җиһазланмаган.

Туфрак катламнарына тискәре йогынты төзелеш-монтаж эшләренең калдыклары барлыкка килә торган территориянең чүпләнүе белән аңлатылачак. Төзелеш барышында шулай ук грунт массаларын чыгару һәм күчерү белән бәйле җир эшләре дә каралган.

Радиация хәлен үзгәртү өчен төзелгән чорда сәбәпләр юк, чөнки радиоактив материаллар куллану каралмаган.

Геологик мохиткә йогынты территория микрорельефы үзгәрү белән бәйле булачак.

Гидрогеологик мохиткә йогынты төзелеш техникасының ягулык-майлау материалларын авария хәлендәге аермаларда пычраткыч матдәләр зонасының пычрануы белән аңлатылырга мөмкин.

Төзелеш чорында тавыш һәм вибрация йогынтысы төзелеш техникасы эше белән бәйле булачак.

Төзелеш чорында үсемлекләр катламына йогынты объектлар төзелеше участокларында ачык ысул белән үсемлек катламын бетерү белән аңлатылачак. Әлеге йогынты төзелеш эшләрен башкару өчен максималь дәрәҗәдә кирәкле чикләр белән чикләнергә тиеш.

Хайваннар дөньясына тәэсир итү төзелеш участокларында җир эшләрен башкарганда туфрак мезофаунасын юк итүгә бәйле булачак. Шулай ук төзелеш эшләре кишәрлек тирәсендәге кошларга тынычсызлык факторы да тудырачак. Әлеге йогынты төзелеш участогы белән чикләнәчәк һәм кыска вакытлы характерда булачак. Төзелеш эшләре зонасының әйләнә-тирәсендәге хайваннар дөньясы озак еллар дәвамында антропоген эшчәнлек тәэсирен кичергәнгә һәм тулысынча яки шактый дәрәҗәдә техноген тирәлектә яшәүгә җайлашканга күрә, проектлана торган эшләрнең сизелерлек йогынтысы көтелми.

Төзелеш барышында шулай ук калдыклар барлыкка киләчәк, бу төзелеш эшләренең төп төрләрен үткәрү белән бәйле (торбаүткәргеч салу территориясен чистарту; вакытлы корылмаларны монтажлау; төзелеш техникасын һәм төзелеш материалларын китерү; эретеп ябыштыру эшләре; изоляция-салу эшләре; төяү-бушату эшләре һ.б.).

Гамәлдәге санитар-экологик таләпләр нигезендә төзелеш калдыкларын вакытлыча туплау аларның төп барлыкка килү урыннарында, ягъни турыдан-туры төзелеш объектына якын урыннарда планлаштырылган, бу бозыла торган җирләрнең мәйданын мөмкин кадәр киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Төзелеш эшләрен башкару чорында өске суларга йогынты ясау территориядән пычранган өске агым барлыкка килүгә китерергә мөмкин. Барлык кирәкле куркынычсызлык чараларын үтәгәндә һәм булган коммуникацияләрнең өзелүенә юл куймаганда, җир асты суларына һәм җир өсте суларына йогынты минималь дәрәҗәдә булачак.

Әйләнә-тирә мохитне пычранудан саклау максатыннан түбәндәге чаралар тәкъдим ителә, аларны гамәлгә ашыру табигать мохитенә тискәре йогынтыны булдырмый калырга яисә максималь киметергә мөмкинлек бирәчәк:

- бары тик төзек транспорт чараларыннан, тулы булмаган яну продуктларыннан двигательләрне чистарту дәрәҗәсен арттыру өчен нейтрализаторлар белән тәэмин ителгән машиналардан һәм механизмнардан файдалану;

- зарарлы матдәләрне чыгару буенча норматив таләпләргә туры китереп, төзелеш машиналарының, механизмнарның һәм транспорт чараларының техник торышынтәэмин итү;

- эш барышында ягулык аппаратурасын җентекләп көйләү;

- төзелеш-монтаж техникасы двигательләренең бушка эшләү озынлыгын кыскарту;

- төзелеш техникасындагы газларның агулы булуын һәм төтенләвен контрольдә тоту;

- машиналарны, механизмнарны һәм автотранспортны билгеләнгән урыннарда ягулык салу;

- тәүлекнең көндезге вакытында машиналарның һәм механизмнарның минималь саны белән төзелеш эшләрен алып бару;

- төзелеш мәйданчыгы буенча автомашиналарның хәрәкәт тизлеген минимальләштерү;

- тавыш дәрәҗәсе рөхсәт ителә торган нормадан арткан җиһазларның эшен булдырмау һәм рөхсәт ителә торган нормадан артык тавыш белән эшләнә торган эшләрне булдырмау;

- радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләренә җавап бирмәгән төзелеш материалларын файдалануны тыю;

- төзелеш техникасын вакытлыча куеп тору, ягулык-майлау материалларын саклау өчен каты өслекле һәм валлар салынган мәйданчык булдыру;

- төзелеш мәйданчыгыннан чыгучы автомобильләрнең көпчәкләрен юу урынын, су үткәрми торган өслек белән җиһазландыру һәм, агып төшүче сулар җыела торган итеп, чистартылганнан соң, аларны кабат куллану;

- түгелгән очракта ягулык-майлау материалларын ком белән җыюны оештыру;

- якындагы су объектына яисә урынның рельефына пычранган хуҗалык-көнкүреш суларын ташлауны тыю, хуҗалык-көнкүреш калдыкларын биобәдрәфкә җыю һәм аларны якындагы су каналы станциясенә чыгару;

- су объектының яр буе полосасыннан һәм су саклау зонасыннан тыш, аңа грунт, лак-буяу материаллары, бензин һ.б. эләгүне булдырмау өчен, вакытлыча складларның урнашуы;

- яр буе полосасыннан һәм су объектларының су саклау зонасыннан читтә көнкүреш, хуҗалык һәм ярдәмче биналар урнаштыру;

- төзелеш агымының рациональ оештырылмавына бәйле рәвештә өстәмә мәйданнарны  нормативтан артык мәҗбүри алуга юл куймыйча, эшләрне катгый бүлеп бирелгән полоса чикләрендә алып бару;

- төзелеш җиһазларын комлы әзерлек буенча тимер-бетон плиталардан урнаштыру мәйданчыкларын төзү;

- төзекләндергәндә алга таба файдалану өчен туфракның уңдырышлы катламын булдыру;

- югалтулар санын, ягулык-майлау материаллары түгелүне киметү;

- территориянең төзелеш чүбе, изоляция һәм башка материаллар калдыклары белән чүпләнүен булдырмау, шулай ук ягулык-майлау материаллары белән пычрануга юл куймау;

- төзелгән шартнамәләр нигезендә лицензиясе булган махсуслаштырылган оешманы утильләштерү яисә күмү өчен алга таба чыгарылган инвентарь контейнерларына калдыкларны үз вакытында җыю;

- төзек булмаган, янгын куркынычы булган транспорт һәм төзелеш-монтаж чараларын куллануны тыю;

- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләрен үтәү;

- кулланыла торган материалларда үсемлекләр дөньясы өчен куркыныч агулы матдәләр булу өлешендә кулланыла торган материалларның сыйфаты ягыннан таләпләргә туры килүен контрольдә тотуны оештыру;

- ГОСТ 17.4.3.02-85 нигезендә туфракның уңдырышлы катламын булдыру һәм аннан соң куллану. Табигый үсемлекләр капламын тизрәк торгызу һәм эрозия процесслары куркынычын киметү максатыннан төзелеш мәйданчыгында (техник) җирләрне реконструкцияләү;

- җирләрне бүлеп бирү чикләрендә чүпләнгән кишәрлекләрне җыештыру;

- кишәрлекләр өслеген сыйфатлы каплау;

- төзелеш эшләре тәмамланганнан соң, территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү;

- хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклау;

- төзелеш техникасының махсус билгеләнгән юл чикләрендә генә йөрүе;

- төзелеш мәйданчыгы чикләрендә эш персоналының көнкүрешен, төзелеш техникасының монтаж һәм ягулык салу мәйданчыкларын урнаштыру;

- җир бүлеп бирү территориясендә техник рекультивация ясауны контрольдә тоту;

- инженерлык челтәрләренең техник торышына мониторинг ясау;

- файдаланыла торган җиһазларга вакытында техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау.

Авария хәлләре килеп чыгу куркынычын киметү өчен техник һәм оештыру чаралары каралырга тиеш, аларны үтәү әлеге куркынычны минимумга җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

Барлык төзелеш эшләре проектта билгеләнгән җир бүлеп бирү чикләрендә үткәрелергә тиеш. Төзелеш-монтаж эшләре җитештерү, төзелеш машиналары һәм транспорт хәрәкәте, эшләр җитештерү проектында каралмаган урыннарда материаллар җыю һәм саклау, шулай ук калдыкларны күмү рөхсәт ителми.

Эшләр уздырганда атмосферага чыгарыла торган пычраткыч матдәләр исемлеген, әлеге йогынтылар ешлыгын сан ягыннан бәяләүне, барлыкка килгән калдыклар төре составын һәм сан ягыннан характеристикасын, эксплуатацияләү чорында йогынты ешлыгын бәяләүне проект документларының «Әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары исемлеге» бүлеге составына кертү максатка ярашлы булачак.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнар оборонасы буенча чаралар башкару кирәклеге турында мәгълүмат**

Алга таба төзелеш барышында челтәрдән биналарга һәм корылмаларга кадәр горизонталь (яктылыкта) минималь ераклык 42.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасының 12.5 таблицасы буенча кабул ителә.

Якындагы инженерлык җир асты челтәрләре арасында горизонталь (яктылыкта) ераклыклар аларны параллель урнаштырганда 42.13330.2016 кагыйдәләр җыелмасының 12.6 таблицасы буенча кабул ителә

Линия объектының санитар-сак зонасы аерым санитар-сак зонасы проекты белән эшләнә һәм билгеләнә.

Проектлана торган объектның гражданнар оборонасы буенча категориясе юк.

Проектлана торган объект гражданнар оборонасы буенча I төркемгә кертелә.

Тикшерелә торган территориядә проектлана торган объектта табигый характердагы гадәттән тыш хәл килеп чыгарга мөмкин булган куркыныч табигый процесслар һәм күренешләр юк.

Территорияне планлаштыру проектында аларның урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналарын билгеләү күздә тотылмый.

_______________